| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК | ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.09.2021 г.Лениногорск № 12

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 августындагы 15 номерлы карары белән раслаңган Лениногорск шәһәре территориясендәге мунчаларның гомуми бүлекчәләрендә Лениногорск шәһәре территориясендә яшәүче бер кеше озатуында инвалид балаларга һәм 6 яшькә кадәрге балаларга, Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм анда катнашучылар, тыл хезмәтчәннәре, пенсионерларга хезмәт күрсәтүче оешмаларга Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 августындагы 15 номерлы карары белән расланган Лениногорск шәһәре территориясендәге мунчаларның гомуми бүлекчәләрендә Лениногорск шәһәре территориясендә яшәүче бер кеше озатуында инвалид балаларга һәм 6 яшькә кадәрге балаларга, Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм анда катнашучылар, тыл хезмәтчәннәре, пенсионерларга хезмәт күрсәтүче оешмаларга Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге өстәмәне кертергә:

Нигезләмәнең 2.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә бирү ярдәм итү чарасын алуның мәҗбүри шарты булып тора.".

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatrstan.ru), интернет-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырыларга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче Р.Р.Сытдиков

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72